ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ – язучы:

К.Сибгатуллин шигырь үлчәвендә татар халкының борынгы бәетләр, дастаннар традициясен дәвам итә, үстерә, баета.

1972 ел, 24 ноябрь, Казан.

Илдар ЮЗЕЕВ – шагыйрь:

Үзенчәлекле каләм иясе һәрбер иске теманы, традицион форманы яңарта, тургайны үзенчә сайрата ала икән... Кадыйр Сибгатуллинның «Ирләр» исемле шигъри әсәрен укыгач, мин тагын бер тапкыр шул хакыйкатьнең хаклыгына ышандым. Кыска гына әсәр тулы бер повесть материалын сыйдырган. Сугыш чорының реаль күренешләре, авыл кешеләренең героик чыдамлылыгы, солдатлар, толлар, балалар язмышы кино экранындагы кебек күз алдыннан уза һәм тормышта күргәндәй тетрәтә.

1973 ел, 20 май, Мәскәү.

Хәсән ТУФАН – шагыйрь:

К. Сибгатуллин – шигъри вакыйга ул.

Әдәбиятта вакыйга дип әйтерлек хәлләр була. Кадыйр Сибгатуллин безнең әдәбиятка гадәти хәл булып кына түгел, вакыйга булып килеп керде. Көтмәгәндә-уйламаганда аның үзенә түгел, ә газетадагы шигырьләренә очрадым. Иң беренче сүзләрендә үк миндә: «Менә бу шагыйрь, тумыштан шагыйрь!» – дигән шатлык туды. Мондый хәлләр сирәк була.

1973 ел, 30 сентябрь, Казан.
Шәхси архивтагы Х.Туфан кулъязмасыннан.

Марсель ГАЛИЕВ – язучы:

Кадыйр Сибгатуллин шагыйрьләргә хас дуамаллык белән җилпенеп-җилпенеп тә алмый, сабыр гына, үз иманын тоеп, җиргә нык басып килә. Аның шигъри образы бераз моңсу, бераз сагышлы, шулай ук күңелендә тормышны яратудан туган яктылык та, бу дөньяның мәңгелегенә ышанган өмет тә бар.

Аның үз темасы, үз җирлеге бар.

1979 ел, ноябрь, Казан.

Марс ШАБАЕВ – язучы:

Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның шигъри сулышы иркен, диапазоны киң. Ул үзе инанганны авыз тутырып, ышандырырлык итеп әйтә белә. Аның үзенә генә хас шигъри күзаллавы, образлар системасы, халыкчан җор үткен теле бар. Купшы матурлык, ялган елтыр бизәкләр исә аның шигъриятендә бөтенләй күренми. Кадыйрда олы гражданлык публицистикасы белән сугарылган хисләр дә, гаҗәеп нечкә лирик моң да бик табигый үрелеп килә.

1986 ел, 4 февраль, Казан.

Зөлфәт (Маликов) – шагыйрь:

Миңа шагыйрьләрнең шагыйрь булып уйнамаганы, шигырь язам дип кыланмаганы, ә бәлки, табигатьнең бер каены шикелле, шигыре белән чын-чынлап шаулаганы кадерлерәк. Кадыйр минем өчен – нәкъ шул шигырь җиле белән шаулаган каен шикелле.

1992, 14 февраль, «Социалистик Татарстан».

Рәшит БӘШӘР – язучы, шагыйрь:

Кадыйр Сибгатуллин һәр искән җил саен кыйбласын үзгәртә торган шагыйрь түгел. Аның иманы нык. Илһам чишмәсе – туган җире, сөекле халкы. Алтмышынчы, җитмешенче, сиксәненче елларда кайбер шагыйрьләр тырышып-тырмашып, җырлый-җырлый

коммунизм төзеп яткан бер мәлдә, ул әрни-әрни «Иргә чыкмый калган апалар», «Ирләр», «Атлар көтте авыл малайлары», «Карт солдат», «Сабан туйлары икән…», «Юлда үскән арыш», «Туган йортта», «Пошилар» кебек ифрат тирән мәгънәле шигырьләр язып, укучыны сискәндерә-сискәндерә яшәде.

1993 ел, 20 апрель, «Шәһри Чаллы».

Хәниф ХӨСНУЛЛИН – журналист, шагыйрь:

Кадыйр Сибгатуллин әдәбиятка үз тавышы, башка беркемне дә кабатламый торган аһәңе белән килеп керде.

Тәбәнәк тауга сокланып, биеклекне белә алмаганнар язмышы читләтеп үтә Кадыйрны – ул шигъриятен Такташ, Туфаннар биеклегенә юнәлтә.

1993

Рәзил ВӘЛИЕВ – шагыйрь:

К.Сибгатуллинның шигърият кыры буйлап ярып килгән буразнасы бара-бара Чаллының киң проспектларына кереп тоташты. Ул элеккеге дәрт һәм илһам белән яңа шәһәр урамнары буйлап җырлап үтте, катлаулы заманның үзәгендә кайнаучы, шул заман уйларын җырлаучы шагыйрь итеп танытты.

«Үткән гомер биктә, капкаларга типмә»,– дип, теләсә кайсы төбәктә яшәүче теләсә кайсы һөнәр ияләре ятлап алырлык фәлсәфи гыйбарәләре дә, өч-дүрт җөмлә белән сурәт-образ ясап куя торган, рәссамнарга хас шигырьләре дә бар.

К. Сибгатуллинның соңгы еллардагы иҗаты «башак шавы» кебек, үткән белән бүгенне, авыл белән шәһәрне тоташтыра, Чаллы биеклегеннән үрелеп, киләчәккә карый.

2000 ел, Казан.

Мансур САФИН – язучы, шагыйрь:

Кадыйр халык тормышын, йөрәген аңлый, замананың сулышын тота белә иде ул. Шуңа күрә аның шигырьләре көчле, талантлы, һәм, ул титан шагыйрь буларак үсеп чыкты. Кадыйрның метафоралары бик көчле.

2000 ел, 15 февраль, Яр чаллы.
Шагыйрьне искә алу кичәсеннән.

Факил САФИН – язучы, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты:

К. Сибгатуллин иҗаты халыкчан фәлсәфәгә нигезләнгән. Алар беренче карашка гади, аңлаешлы. Шушы гадилек күңелләрне җәлеп итә, аның шигъриятен илаһи биеклеккә күтәрә. Тик, ассызыклап әйтергә кирәк, гади генә шигырь юллары артына зур мәгънә яшерелгән. Аларны күрү бәхете зәвыклы укучы өлешенә генә тия.

2001 ел, 9 февраль,«Мәдәни җомга», Казан.

Айдар ХӘЛИМ – язучы, публицист:

Кадыйр Сибгатуллин татар язмышында егерменче гасырның икенче яртысында иң зур әһәмияткә ия булган классик шагыйрьләребезнең берсе. Аның шигъриятенең никадәр нечкә образларга нигезләнгәнен әле аңлап җиткермибез. Татар милләтенең туксан тугыз проценты бүген читкә китә. Менә кайсы яктан карарга кирәк – югалтулар турында.

2001 ел, 26 февраль, Яр Чаллы.
Шагыйрьнең «Осенняя весна» китабын
тәкъдир итү кичәсеннән.

Зөләйха МИНҺАҖЕВА – шагыйрә:

Халкыбызның буыннардан буыннарга күчәчәк горурлыгы булган бөек шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның шигырьләрен мин көндәлек шикелле, үземнең кәефемә карап, җавап эзләгәндә актарам, һәм, әлбәттә, җавап аның шигырьләре арасында бар.

2002 ел, 9 апрель, Яр Чаллы.

С.Садыйкова ис. Концертлар залында узган
60 еллык юбилей кичәсеннән.

Чәчкә ХӨСНЕТДИНОВА – журналист,
«Осенняя весна» (1999) китабының редакторы:

Кадыйр Сибгат халкы, милләте, гомумән, кешелек җәмгыяте тормышының барометры булган иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге полотнолар белән беррәттән, тирән хиссият тулы лирик әсәрләр дә иҗат итте. Моңнары түгелеп торган ул шигырьләргә дә мәгънә тарлыгы, шәхсилек, җиңеллек ят, алар Кадыйр абыйга гына хас гомумиләштерү осталыгы белән шулай «бөтерелгән» – укуга, шагыйрьнең синең җанның да халәтен ничек нечкә тоюына, ничек рас сурәтләвенә таң каласың. Ул сурәтләү дә гади, тапталган түгел, катлаулы...

«Минем шигырь – үзе җыр», – дип, һич кенә дә ялгышмаган Кадыйр абый. Ишетәсезме, ул нәрсә ди:

«Сез җырлагыз!
Үзем дәшмәсәм дә,
сезнең белән җырлый йөрәгем...»

Шагыйрьне сагыну, юксыну исә гомер бакый тынмас, басылмас инде...

Яр Чаллы, 2002.

Нияз АКМАЛ – шагыйрь:

Кадыйр Сибгатуллинның иҗатын, аның шигъриятен – милли шигъриятне Академия Наук дәрәҗәсендә өйрәнергә зарур. Академиклар өйрәнерлек фәлсәфә, мантыйк, этика, эстетика... Ул – зур укытучы, сабак бирерлек укытучы.

2007 ел, 20 апрель, «Чаллы ТВ».

Вахит ИМАМОВ – язучы:

Талантлы кеше – ул талантсызлар өчен һәрвакыт куркыныч кеше. Кадыйр абыйның үзе җиһаннан киткәненә ничә еллар булса да, бүген дә исәннәр өчен конкурент.

2008 ел, 29 ноябрь, Яр Чаллы.
«Бер ноктада» китабын тәкъдир итү кичәсеннән.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН – филология фәннәре докторы, профессор:

Кадыйр Сибгатуллин шигъриятендә заман сулышы. Аларны Кадыйр Сибгатуллин үзе генә түгел, кулыннан тотып заман, халык яздырган.

«Кадыйр Сибгатуллин шиъриятендә заман сулышы».
Конференция материалларыннан. 2008 ел.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ – язучы:

Кадыйр Сибгатуллинның шәхесе дә, аның иҗаты да инде бер фәнни-гамәли конференция рамкаларына гына әлбәттә сыеша торган шәхес тә, иҗат та түгел. Аның шәхесе дә, иҗаты да шактый киң мәгънәгә ия.

...Милләтпәрвар шәхесебезнең бүгенге көндәге мирасы өйрәнелергә тиеш, пропагандаланырга тиеш.

Чаллы телевидениесында «Чал тарихлы кала»
тапшыруындагы чыгышыннан, 20.04.2007.

Вәзыйх ФАТЫЙХОВ – журналист, шагыйрь:

Кадыйр Сибгатуллин – татар әдәби теленең камиллеге өчен чын күңеле аша каләме көчендә көрәшкән иҗади бунтарь да.

«Кадыйр Сибгатуллин – журналист һәм остаз».
Конференция материалларыннан, 2008 ел.

Әнвәр ШӘРИПОВ – филология фәннәре докторы, профессор:

Кадыйр – философ шагыйрь. Аның әсәрләре үзенә халкыбыз зирәклеген, халык акыл-фәлсәфәсен туплаган. Кадыйрның мәкаль-әйтем булып китәрдәй зирәк фикерләренең берничәсе: «Башлык шагыйрь булса ярый, шагыйрь башлык булмасын»; «Балаларга һаман чират җитми, тәрбиягә мохтаҗ өлкәннәр»; «Гомер яшел чакта уйлар яшел. Көзләр җиткәч, уйлар зирәкләнә»; «Уйлый кеше, уйлый гомер буе, үзеннән соң кала шул ук уе. Бер гомерен яшәп кеше китә, калган уе мең гомергә җитә»; «Ваклыкларга – шундый серен беләм – түләү кирәк икән эредән»; «Моңлы җаннар җирдә булмас иде, моңлы дөнья әгәр булмаса»; «Бәхет алып киләләр дә сиңа, бәхетеңне алып китәләр. Хәсрәт төяп киләләр дә сиңа, бер бәхетле бәндә итәләр»; «Туган көннәр килә кисәтергә кадерен бел диеп гомернең».

«Кадыйр Сибгатуллин шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеше».
Конференция материалларыннан. 2008 ел.

Әлфия ШАКИРҖАНОВА – Татарстанның атказанган укытучысы, доцент:

Кадыйр Сибгатуллин – иленә, халкына җаны-тәне белән бирелгән шагыйрь. Аңардагы ватандарлык гади татар авылындагы гади бер ишектән атлап чыга да, илләр-кыйтгалар кичеп, олуг патриотизм хисе булып үсә, күтәрелә.

«Шагыйрь К.Сибгатуллин иҗатында
шәфкатьлелек мәсьәләләре».
Конференция материалларыннан. 2008 ел.

Дания НИГЪМӘТҖАНОВА – филология фәннәре кандидаты:

Кадыйр Сибгатуллин. Аның җырларында дөнья авазы. Табигать һәм җәмгыятьтәге вакыйгаларга, күренешләргә сизгер, үз күзе белән карап, үз йөрәге белән тойган нәфис гаять тирән чынбарлык бар.

«Кадыйр Сибгатуллин иҗатында лирик-фәлсәфи юнәлеш».
Конференция материалларыннан. 2008 ел.

Рәзинә МӨХИЯРОВА – шагыйрә, филология фәннәре кандидаты, профессор:

Кадыйр Сибгатуллин үзе дә татар шигърияте кырында «почмагы нык», «нигезе нык» биек эскерт салып калдырган игелекле илаһи зат.

«Кадыйр Сибгатуллинның «Кибәнче карт» балладасы».
Конференция материалларыннан. 2008 ел

ОТЗЫВЫ О ТВОРЧЕСТВЕ ПОЭТА

Хасан ТУФАН – поэт, классик татарской литературы:

К. Сибгатуллин – поэтическое явление.

Я нежданно-негаданно встретил не его самого, а его стихотворенрия в газетах. С первых же строк в меня вселилась радость: это настоящий поэт, поэт от рождения!

Из Рекомендации в СП СССР, 1973 г., 30 сентября.

Нури АРСЛАНОВ – поэт:

В стихотворениях поэта народная мудрость, простота, ему чужда созерцательное отношение к событиям, свойственна глубокая проницательность, искреннее переживание, тонкое понимание своих, самим описуемых героев. Он умеет оказать эмоциональное влияние на своего читателя,

заставлять его переживать вместе с собой и с теми, которые изображены на своем поэтическом полотне. Как известно, именно эти качества делают стихи стихами, поэта – поэтом.

Казань, 16 мая 1973 года.

Юрий ЛАССКИЙ – рецензент:

Перед нами интересный, самостоятельно мыслящий и тонко чувствующий поэт. Поначалу поэтическая манера Кадыйра Сибгатуллина в чем-то даже озадачивает. К его стилистике и способу поэтического мышления нужно привыкнуть, понять принципы его поэтики – один из основных признаков подлинного писательского дарования.

Но поэт на то и поэт, чтобы трещина мира проходила через его сердце, как бессмертно выразился Генрих Гейне. Каким же на этот день был для мира? Для мира, в котором столько чудовищных трещин, какие не могли и помыслиться в самом страшном кошмаре не только в 19-веке, но и сорок лет назад... Одна единственная строка дает нам физически ощутимую картину происходящего сегодня на нашей Земле: «От земного шара несло запахом гари».

Поэт заставляет нас остановиться и задуматься. «Много вопросов рождалось сегодня на Земле. // Многим вопросам нашлись ответы. //У меня лишь один вопрос // раной живой лежит на душе: //уже ведь осень, //куда идут лоси?» («Лоси»).

Кадыйр Сибгатуллин пишет спокойно:

«Не у поэтов,

у компьютера

чувствительнее сегодня чутье».

Прав он? Прав, как был бы прав и другой поэт, сказавший обратное, если бы он доказал это поэтическими средствами. Кадыйр Сибгатуллин доказывает. Но доказывает свои слова он в большинстве случаев без форсирования интонации, доказывает – показывая, рассказывая – убеждает.

Из Рецензии на сборник стихотворений и поэм
(подстрочники) Кадыйра Сибгатуллина. 2 июня 1985 г., Москва.

Мария АВВАКУМОВА – член Союза писателей России:

Поэтическое видение, поэтическая фантазия помогают поэту. Он хорошо распоряжается богатствами родного языка – русскому читателю будет интересно прикоснуться к ним, если, конечно, переводчик найдет возможность их сохранить.

Поэт чувствует природу. У природы он учится оптимическому мировосприятию. И надо сказать – он умеет сказать бодро, ибо истинно любит свою землю:

«Счастье в родной стороне, не ищите счастья где-то в далеке».

Сибгатуллин не занимается словесной «джигитовкой». Он живет в своей поэзии настоящей жизнью мужчин: берет на свои плечи тяжелый груз гражданственности, серьезного гуманизма – и несет сколько может.

3 июня 1985 г., Москва.

М. АКЧУРИН – ст. редактор Издательства «Современник»:

Разнообразию мыслей и чувств поэта соответствует и разнообразие лирических

жанров. Здесь есть и философская , и любовная, и пейзажная, и гражданская лирика.

Почти в каждом стихотворении есть некая неожиданность, свидетельствующая об истинности поэтического факта, о том, что «Поэзия здесь ночевала» – если можно так перефразировать известное выражение.

Привлекает в стихах К.Сибгатуллина и тонкая ироничность, преходящая порой в самоиронию, удачно соединяющую в себе один из признаков современного городского интеллектуала с древнейшей татарской национальной традицией, согласно которой все острословы считаются таковыми, если прежде всего умеют шутить над собой. Читателя ждет встреча с творчеством еще одного очень незаурядного поэта, способного достойно представлять национальную литературу на всесоюзной, как говорится, арене.

Редзаключение на рукопись К. Сибгатуллина

«Зов мечты» (построчные переводы с татарского), 1985 г.

Владимир ШРАМКО – писатель:

Главный учитель Кадыйра Сибгата в поэзии – народ, его поэтическое творчество. Язык народной песни, бытовая народная речь – все впитано, усвоено, все родное с детства. Это язык его матери, первое, что услышал и полюбил, придя в жизнь.

Кадыйр Сибгат вступил в поэзию, отдавая дань городской индустриальной нови, но и сохранивши первоизданно чистую народную речь. Поэту хочется свою малую родину, беззаветно любимую, представить равной среди других поэтических держав.

22 апреля 1993 г., «Известия Татарстана», Казань.

Равиль САБИРОВ – писатель, драматург:

Евгений Батенчук, Раис Беляев, Марат Бибишев, Лев Васильев, Кадыйр Сибгат и Индус Шакуров. Эксперты «Вечерки» признали их самыми выдающимися челнинцами за всю историю города. Все эксперты написали: «Подкупает их умение всецело отдавать себя служению делу и любить людей». Еще раз доказав истинность высказыывания «Поэт в России – больше чем поэт», наши эксперты проголосовали за безвременно ушедшего от нас в 1994 году татарского поэта Кадыйра Сибгата.

«Вечерние Челны». 2003. 17 сентября.

Иван СОЧНЕВ – художник, автор портрета «К.Сибгатуллин»:

Прочитав произведения Кадыра, переведенные издательством «Современник», я для себя открыл талантливого поэта, познакомился с его произведением – эссе о Каме, о развалинах Булгар, о его беспокойстве о настоящем времени и о будущем. Стихи его, на первый взгляд, кажутся простыми, но в каждом в них заложена большая философия, большая любовь к людям.

15 февраля 1997 г., Набережные Челны.

Рахмай ХИСМАТУЛЛИН – писатель:

Кадыйр ворвался в большую литературу как таран, минуя пору ученичества. Он писал очень просто и об очень простых вещах, однако все им написанное состоит из афоризмов: «Мучаются в тягостном одиночестве объятий, расписанных загсом», «если душа моя еще жива, то можете кусочек от нее отрезать и себе», «Так тянет земля к себе, что даже рост мой невысок», «Нежданно полонила душу зеленая грусть-печаль», «Начало

посевной сегодня – кипит в котлах гороховый суп с мясом!». Хочется и самому окунуться в мир афоризмов. Волшебство неповторимо!

1999.

Александр ЗОРИН – переводчик:

Здравствуй, дорогой Кадир! ...Основной тембр книги – лирический. Как мы ее назовем? Подумай и ты. Пришли мне несколько названий. Если, конечно, редактор разрешит нам заменить.

...Редактор у нас – женщина. Цитирую тебя: «Ох, женщины, вы все немножко вздорны». Но мы, мужчины много видевшие, постараемся найти для них убедительные слова.

21 августа 1977 г. Семхоз.

...Да, я ждал твоего письма, чтобы внести исправления. И тем не менее сдал книгу в издательство. ...Я дал книге название «Шум деревьев перед рассветом». У тебя есть такое стихотволрение. Главный редактор заподозрил подтекст. Трусливые чиновники, они сами за себя боятся, и на каждом шагу перестраховываются. ...Но – ничего. Мне нравится наша книга. Она ровная и колоритная.

19 сентября 1977 г. Новгородская обл., Валдайский р-н.

Дорогой Кадир! Наконец-то посылаю тебе книгу, которая, как я предпологал, претерпела тяжелые испытания в процессе редактирования. Ей, что называется сделали правопускание трижды... В моей практике такого тотального урезывания еще не было. Возможно потому, что я имел дело с более самостоятельными, более независимыми редакторами, способными защищать свое мнение.

...Словом, поэт должен состояться на родном языке, а на чужом – вне его возможностей. К тому же, если за переводом на чужой язык стоят явные политические причины.

6 декабря 1977 г., Москва.

Кадир! Прости за спешность. Книга называется «Полет радуги». Выйдет не раньше августа. …Какие стихи взяла «Литературная Россия» не помню, да на этот вопрос лучше ответит Дементьев. Но не бойся их сдублировать – наша авторская совесть защищена теми выкинутыми из книги стихами, которых ни разу не напечатают.

2 февраля 1978 г., Москва.